КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 февраль г.Казань № 96

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары структурасы һәм штат расписаниесен раслау турында» 2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының җәмәгать судьялары аппаратлары структурасын һәм штат расписаниесен раслау турында» 2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 21 декабрь, 738 нче; 2010 ел, 29 ноябрь, 957 нче; 2013 ел, 9 август, 556 нчы; 2013 ел, 11 декабрь, 976 нчы, 2014 ел, 17 март, 163 нче, 2016 ел, 14 гыйнвар, 11 нче; 2016 ел, 11 май, 294 нче; 2017 ел, 29 сентябрь, 732 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1069 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «3 012 067,0» саннарын «3 020 358,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларының штат расписаниесен бу механизмга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 12 ноябрь, 626 нчы
карар белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 19 февраль,96 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларының
штат расписаниесе

| Вазыйфа исеме | Саны, берәмлек | Вазыйфаи оклад, тариф ставкасы, сум | Хезмәткә түләүнең айлык фонды, тариф фонды, сум |
|---|---|---|---|
| Консультант | 152 | 4 666,0 | 709 232,0 |
| Суд утырышы секретаре | 188 | 4 666,0 | 877 208,0 |
| 2 разрядлы өлкән белгеч – канцелярия мөдире | 145 | 3 729,0 | 540 705,0 |
| 2 разрядлы белгеч | 173 | 3 507,0 | 606 711,0 |
| Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте хезмәткәрләре барлыгы | 658 | | 2 733 856,0 |
| Өлкән белгеч | 14 | 5 140,0 | 71 960,0 |
| 5 нче разрядлы җиңел автомобиль йөртүче | 2 | 2 953,0 | 5 906,0 |
| Биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау буенча 4 разрядлы эшче | 5 | 2 660,0 | 13 300,0 |
| Биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау буенча 3 разрядлы эшче | 15 | 2 539,0 | 38 085,0 |
| Җитештерү һәм хезмәт урыннарын 2 разрядлы җыештыручы | 64,5 | 2 438,0 | 157 251,0 |
| Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кертелмәгән хезмәткәрләр барысы | 100,5 | | 286 502,0 |
| Җәмәгать судьялары аппаратлары буенча барлыгы | 758,5 | | 3 020 358,0 |